ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**10.11.2020**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 2142**

Зеленодольск муниципаль районы буенча 2020 елның IV кварталына гомуми торак мәйданының 1 квадрат метрының уртача базар бәясе турында

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «2020 елның IV кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» 2020 елның 29 сентябрендәге 557/пр номерлы Боерыгы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Күрсәтелгән социаль түләүләр федераль бюджет акчалары исәбеннән торак урыннар сатып алуга (төзүгә) бирелә торган барлык категориядәге гражданнар өчен социаль түләүләр күләмнәрен исәпләп чыгарганда, 2020 елның IV кварталына Зеленодольск муниципаль районы буенча гомуми торак мәйданының 1 квадрат метрының (сумнарда) уртача базар бәясен 53 919 (илле өч мең тугыз йөз унтугыз) сум күләмендә расларга,
2. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Матвеевка йөкләргә.

Җитәкче И.Р. Ганиев